РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» 06 2020 г. №404

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясе составын һәм Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Ютазы районы советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә таянып, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен камилләштерүгә бәйле мәсьәләләрне объектив, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә теркәлгән гражданнарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясе составын расларга (Кушымта №1).

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясе турында” Нигезләмәне расларга (Кушымта №2).

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы район торак-

көнкүреш комиссиясен яңа составта раслау турында» 2020 елның 26 февралендәге 105 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ә. Шафигуллин

Н.А. Әбилтарова
2-76-81

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль
районы
Башкарма комитетының
карарына
«___»_______ 2020 ел № _____

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Шафигуллин А.Ә. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Самонина С. П. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Әбилтарова Н.А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлеге башлыгы, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Шәрипов Р. Ә. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Якупов Р. М. | Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хәмидуллин Л. А. | полиция өлкән лейтенанты, Ютазы районы буенча Эчке эшләр министрлыгының НЭБ һәм ПК өлкән оперуполномоченные (килешү буенча) |
| Катеева Д. А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе ( килешү буенча ) |
| Галләмова Р. А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Шәрифуллин В.А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Шуть А. Р. | БТИ РГУП №11 Ютазы төркеме җитәкчесе (килешү буенча) |
| Рәшитова З. Ә. | Ютазы муниципаль районында Татарстан |

| | |
|---|---|
| | Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Яһудин И. А. | “Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды” КБОның Әлмәт МРП җитәкчесе (килешү буенча) |
| Борисов А. В. | ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының<br>Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы |

Кушымта № 2<br>Татарстан Республикасы<br>Ютазы муниципаль<br>районы<br>Башкарма комитетының<br>карарына<br>«___»_______ 2020 ел № _____

**«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясе турында»**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1.Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясе (алга таба-комиссия) җирле үзидарә органнары вәкаләтләре нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә теркәлгән гражданнарга торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу һәм социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибен камилләштерүгә бәйле мәсьәләләрне объектив, һәрьяклап карау максатында төзелгән даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.2. Комиссия Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән (алга таба – Башкарма комитет) төзелә.

1.3. Комиссия составы Башкарма комитет җитәкчесе карары белән раслана.

1.4. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы торак законнарына, башка норматив һәм хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

**2. Комиссиянең төп бурычлары**

Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

2.1. Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен гражданнар гаризаларын карау;

2.2. «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар

буларак гражданнарны исәпкә алу турында карар чыгару өчен кирәкле гаризага теркәлгән документларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

2.3. Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу һәм исәпкә алудан баш тарту турында карарлар әзерләү;

2.4. Исәпкә алу турында гражданнарның гаризаларын, учетка алу кенәгәсен, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алынган гражданнарны исәпкә алу Кенәгәсен, законнар нигезендә исәпкә алынган гражданнарның исәпкә алу эшләрен теркәү Кенәгәсен тутыру һәм алып бару дөреслеген контрольдә тоту.

## 3. Комиссия составы

3.1. Комиссия рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

3.2. Комиссия составына җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары һәм башка оешмалар вәкилләре керә ала.

3.3. Комиссия рәисе булып тора. Комиссия рәисе булмаганда, аның бурычлары комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

3.4. Кворум өчен комиссия составы әгъзалары саны кимендә 5 (биш) кеше булырга тиеш.

## 4. Комиссия эшчәнлеген оештыру

4.1. Комиссия рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра.

4.2. Комиссия утырышлары расланган план нигезендә, әмма айга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Утырышларда комиссия әгъзаларының 50% тан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Җирле үзидарә органнары яисә юридик зат тарафыннан вәкаләтле вазыйфаи зат гражданнарны исәпкә алу мәсьәләсен карау өчен кирәкле документларны әзерли.

4.4. Комиссия утырышында карала торган мәсьәләләр гражданнарны торак урыны алу өчен исәпкә алу (баш тарту) буенча комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.5. Комиссия карары, утырышта катнашучыларның күпчелеге аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Комиссия карары тәкъдим итү характерына ия.

4.6. Комиссия карарын исәпкә алып, Башкарма комитет җитәкчесе 3 эш көне эчендә гражданнарны исәпкә алу (баш тарту) турында боерык, гаиләне исәпкә алудан төшерү турында күрсәтмә әзерли.

4.7. Җирле үзидарә органнары вәкаләтле вазыйфаи заты 5 эш көне эчендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләр реестрын төзи, аны Башкарма комитет җитәкчесе раслый.

4.8. Комиссия исәп эшләрен формалаштыру, алып бару, аларның дөреслеген контрольдә тоту, законнар нигезендә торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алынган гаиләләрнең локаль исемлекләрен тиешле дәрәҗәдә тоту эшендә катнаша.

4.9. Комиссия ел саен (киләсе елның 1 апреленә кадәр) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм гамәлдәге законнар нигезендә торак шартларын яхшырту өчен гариза биргән гражданнарны яңадан теркәүне уздыруда катнаша.

## 5. Иҗтимагый торак комиссияләренең җаваплылыгы

Комиссия әгъзалары реестрны формалаштыру, исәп эшләрен алып бару һәм гамәлдәге законнар нигезендә торак шартларын яхшырту өчен гаиләләрнең локаль исемлекләрен саклау буенча җаваплы.